Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, №5; 2007, №2-3, № 11) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. **Гражданның язма рәвештә, электрон документ рәвешендә бәян ителгән мөрәҗәгате**";

б) дүртенче өлештә "бу хакта" сүзләре алдыннан "мөрәҗәгать теркәлгән көннән соң җиде көн эчендә" сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле бишенче өлеш өстәргә:

"Органга яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать законнарда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта), әгәр җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиеш булса, электрон почта адресын, әгәр җавап язма рәвештә җибәрелергә тиеш булса, почта адресын катгый рәвештә күрсәтә. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә өстәп куярга йә күрсәтелгән документларны һәм материалларны яисә аларның күчермәләрен язма рәвештә җибәрергә хокуклы.";

2) 16 статьяда:

а) 2 пунктта "мөрәҗәгать итәргә" сүзләре алдыннан ", шул исәптән электрон рәвештә" сүзләрен өстәргә;

б) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9) мөрәҗәгатьне караганда органның яисә вазыйфаи затның законсыз гамәле (гамәл кылмавы) аркасында китерелгән зарарны законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтергә һәм мораль зыян өчен компенсация алырга.";

3) 17 статьяда:

а) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"мөрәҗәгатьне карау өчен кирәкле документларны һәм материалларны башка органнардан һәм башка вазыйфаи затлардан (судлардан, башлап сорау алу органнарыннан һәм алдан тикшерү органнарыннан тыш) кирәк булганда соратып алырга, шул исәптән электрон рәвештә дә, шулай ук вазыйфаи затлардан аңлатмалар алырга, шаһитларны һәм экспертларны чакырырга;";

б) алтынчы абзацта "язма рәвештә" сүзләре алдыннан "мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча" сүзләрен өстәргә, "язма рәвештә" сүзләреннән соң ", мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә" сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 25 декабре
№ 102-ТРЗ